**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об отмене карантина, установленного на территориях некоторых населенных пунктов Азнакаевского района Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с истечением двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством и выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^{1}$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить карантин, установленный в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных на территориях следующих населенных пунктов Азнакаевского района Республики Татарстан:
деревня Октябрь-Буляк;
деревня Маняуз.

2. Признать утратившими силу:
Указ Президента Республики Татарстан от 15 марта 2019 года № УП-165 «Об установлении карантина на территории деревни Октябрь-Буляк Азнакаевского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных»;
Указ Президента Республики Татарстан от 15 марта 2019 года № УП-166 «Об установлении карантина на территории деревни Маняуз Азнакаевского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
23 мая 2019 года
№ УП-293

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Азнакай районының кайбер торак пунктлары территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай районының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:
Октябрь-Бүләк авылы;
Мәнәвез авылы.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:
Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Азнакай районының Октябрь-Бүләк авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2019 елның 15 мартындагы ПУ-165 номерлы Указы;
Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Азнакай районының Мәнәвез авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2019 елның 15 мартындагы ПУ-166 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 23 май
№ ПУ-293